| ГЛАВА СРЕДНЕКАМЫШЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРТА КАМЫШЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | Урта Камышлы | **КАРАР** |

**«30» октябрь 2019 ел** **№ 3**

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы җирлегенең Абляскино авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Урта Камышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2019 елның 15 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Абляскино авылы, Пушкин тыкрыгы, 3 нче йорт адресы буенча урнашкан мәктәп бинасында Урта Камышлы авыл җирлеге Абляскино авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2019 елның 15 ноябрендә 12 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Абляскино авылы, Пушкин тыкрыгы, 3 нче йорт адресы буенча урнашкан мәктәп бинасында Урта Камышлы авыл җирлеге Абляскино авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен Абләскино авылында яшәүчеләрнең исемлеген аеруны сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

4. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эшләре Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2020 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Абляскино авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр

балигъ булмаган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә җибәрүгә килешәсезме?:

- торак пункт чикләрендәге юлларны ремонтлау.
- су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр башкару
- роторлы чапкыч сатып алу.

«ӘЙЕ» «ЮК»

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегенең Абляскино авылы мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы Н.А. Баймяшкина